Татарстан Республикасы
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

БОЕРЫК

2015 елның 15 гыйнвары Казан ш. № 3/2-пр

**2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Хокүмәтенең “Нәселле терлекчелеккә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2012 елның 4 декабрендәге 1257 номерлы, “Үсемлекчелекнең аерым тармакларына ярдәм итү очен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 12 декабрендәге 1295 номерлы, “Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган товар сотнең 1 литрына (килограммына) чыгымнарының бер олешен каплау очен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 22 декабрендәге 1370 номерлы, “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 27 декабрендәге 1431 номерлы карарлары нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Субсидияләр бирүнең кушымта итеп бирелгән түбәндәге тәртипләрен расларга:

1.1. 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек олкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта);

1.2. 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең элиталы орлык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (2 нче кушымта);

1.3. 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау чыгымнарының бер олешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (3 нче кушымта);

1.4. 2015 елда файдаланылмый торган иске бакчаларны топләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультивацияләү чыгымнарының

бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (4 нче кушымта);

1.5. 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) сөт чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (5 нче кушымта);

1.6. 2015 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен (6 нчы кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

дәүләт ярдәмен алучылар квартал беткәннән соң 20 календарь көн эчендә, ел беткәннән соң 60 календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) авыл хуҗалыгы товарларын житештерүчеләрнең (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) финанс-икътисадый торышы турында хисап тапшыралар;

Идарәләр Министрлыкка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең финанс-икътисадый торышы турында җыелма хисап тапшыралар;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр финанс-икътисадый торышлары турында хисапны үз вакытында тапшырмасалар, Министрлык дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне туктатып торырга хокуклы.

3. Тапшырыла торган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылыкны субсидияләрне алучы оешмаларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләргә.

4. Министрлыкның финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка:

4.1. Әлеге боерыкның 1 пунктында каралган тәртипләр нигезендә Министрлыкның финанс бүлеге белгечләре тарафыннан документлар кабул итүне тәэмин итәргә.

4.2. Дәүләт ярдәмен алучылар финанс-икътисадый торышлары турында хисапларны үз вакытында тапшырмасалар, дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне туктатып торырга.

5. Министрлыкның түбәндәге боерыкларының үз көчләрен югалтуын танырга:

“2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 25 апрелендәге 91/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек

министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 28 маендагы 105/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме очен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 24 июнендәге 114/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме очен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 13 августындагы 156/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 15 сентябрендәге 175/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 5 декабрендәге 230/2-пр номерлы;

“Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 9 декабрендәге 233/2-пр номерлы.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

# 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип милекчелек формаларына бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату белән шөгыльләнүче үз чәчүлекләре булган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен 2015 елда субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, субсидияләр алучылар).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерие буларак үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату алына.

3. Субсидияләр бирү шарты буларак 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче милкендә яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре булу билгеләнә.

Субсидияләр бетерелү стадиясендәге яки үз-үзен тәэмин итә алмаган (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелми.

4. Субсидияләр бирү максатлары:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең 1 гектар чәчү мәйданына исәпләгәндә агротехник эшләр комплексын уздыру чыгымнарының бер өлешен каплау;

авыл хуҗалыгы производствосының экологик куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру;

туфракның ундырышлылыгын һәм туфрак сыйфатын арттыру.

5. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр өчен 1 гектар чәчү мәйданына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$V = П \times (125{,}0 + (2{,}0 \times У) + (42{,}0 \times И_{ппмр}))$,

монда:

V – күчерелергә тиешле субсидияләрнең күләме, сум;

П – гектарда исәпләнгән чәчү мәйданы, ул факттагы чәчүлекләр мәйданнары турындагы мәгълүмат белән дәлилләнә, мәгълүмат нигезендә исә 2014 ел уңышын җыеп алу турында рәсми статистик хисап төзелә (алга таба – уңыш җыеп алу турында мәгълүмат);

125,0 – бер гектар чәчүлек мәйданына минималь ставка, сум;

2,0 – ашлык берәмлекләрен җитештерүнең 1 центнерына ставка, сум;

У – авыл хуҗалыгы культураларының уртача уңдырышлылыгы, ул Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Авыл хуҗалыгы культураларын ашлык берәмлекләренә күчерү коэффициентларын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгына ярашлы рәвештә 2014 елга уңыш җыеп алу турында мәгълүматка нигезләнеп 1 гектар чәчүлектән алынган ашлык берәмлекләре центнерларында күрсәтелә.

42,0 – чәчүлекнең бер гектарына җирләрнең уңдырышлылыгы буенча уртача ставка, сум;

$И_{ппмр}$ – Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча туфрак уңдырышлылыгының уртача алынган индексы, ул әлеге тәртипкә кушымта нигезендә “Татарский” агрохимия хезмәте үзәге” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе һәм “Әлмәт” агрохимия станциясе” Федераль дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – агрохимия хезмәтләре) тарафыннан тапшырылган мәгълүматларга нигезләнеп Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының “Россия Федерациясе субъектында туфрак уңдырышлылыгы күрсәткечләрен исәпләү методикасын раслау турында” 2013 елның 11 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы белән расланган методика нигезендә билгеләнә.

6. Әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

2014 ел уңышын җыеп алу турында рәсми статистик хисап төзелгән (алга таба – уңыш җыеп алу турында хисап), субсидияләр алучылар тарафыннан таныкланган мәгълүматны;

бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмәсен.

7. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел;

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисап белешмәсен Министрлык раслаган форма буенча төзи һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру;

бюджет йөкләмәләренең калган лимиты булмау.

8. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган җыелма исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора. Идарә субсидияләрне 5 эш көне эчендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

9. Министрлык Министрлык белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

10. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылса, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

15. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.

2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

## Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр күләмен исәпләү өчен туфрак уңдырышлылыгы индексы

| № т/б | Муниципаль район исеме | Агрохимия хезмәтләре белешмәләре буенча туфрак уңдырышлылыгы коэффициенты ($К_{мр}$) | Туфрак уңдырышлылыгы индексы ($И_{пп.мр}$=71,05/$К_{мр}$) |
|---|---|---|---|
| 1 | Әгерҗе | 75 | 0,9473 |
| 2 | Азнакай | 93 | 0,7640 |
| 3 | Аксубай | 82 | 0,8665 |
| 4 | Актаныш | 84 | 0,8458 |
| 5 | Алексеевск | 85 | 0,8359 |
| 6 | Әлки | 62 | 1,1460 |
| 7 | Әлмәт | 81 | 0,8772 |
| 8 | Апас | 78 | 0,9109 |
| 9 | Арча | 73 | 0,9733 |
| 10 | Әтнә | 66 | 1,0765 |
| 11 | Баулы | 84 | 0,8458 |
| 12 | Балтач | 76 | 0,9349 |
| 13 | Бөгелмә | 95 | 0,7479 |
| 14 | Буа | 86 | 0,8262 |
| 15 | Югары Ослан | 69 | 1,0297 |
| 16 | Биектау | 70 | 1,0150 |
| 17 | Чүпрәле | 87 | 0,8167 |
| 18 | Алабуга | 67 | 1,0604 |
| 19 | Зәй | 79 | 0,8994 |
| 20 | Зеленодольск | 74 | 0,9601 |
| 21 | Кайбыч | 79 | 0,8994 |
| 22 | Кама Тамагы | 76 | 0,9349 |
| 23 | Кукмара | 73 | 0,9733 |
| 24 | Лаеш | 76 | 0,9349 |
| 25 | Лениногорск | 82 | 0,8665 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 26 | Мамадыш | 70 | 1,0150 |
| 27 | Менделеевск | 71 | 1,0007 |
| 28 | Минзәлә | 68 | 1,0449 |
| 29 | Мөслим | 82 | 0,8665 |
| 30 | Түбән Кама | 73 | 0,9733 |
| 31 | Яңа Чишмә | 74 | 0,9601 |
| 32 | Нурлат | 72 | 0,9868 |
| 33 | Питрәч | 69 | 1,0297 |
| 34 | Балык Бистәсе | 72 | 0,9868 |
| 35 | Саба | 70 | 1,0150 |
| 36 | Сарман | 86 | 0,8262 |
| 37 | Спас | 60 | 1,1842 |
| 38 | Тәтеш | 82 | 0,8665 |
| 39 | Тукай | 81 | 0,8772 |
| 40 | Теләче | 69 | 1,0297 |
| 41 | Чирмешән | 80 | 0,8881 |
| 42 | Чистай | 72 | 0,9868 |
| 43 | Ютазы | 91 | 0,7808 |
| **ТР буенча уртача :** | | **71,05** | **1,0000** |

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр
номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең элиталы орлык сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) сатып алынган элиталы орлыклар – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган Дәүләт селекция казанышлары реестрына кертелгән, кулланылуы рөхсәт ителгән сортлар чыгымнарының бер олешен каплау очен 2015 елда субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу очен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерие буларак үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату алына.

3. Субсидияләр бирү шарты буларак 2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче милкендә яки аренда шартларында авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре булу билгеләнә.

Субсидияләр бетерелү стадиясендәге яки үз-үзен тәэмин итә алмаган (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелми.

4. Субсидияләр бирү максатлары уңышны һәм үсемлекчелек продукциясен җитештерүне арттырудан гыйбарәт.

5. Авыл хуҗалыгы культураларының исемлеге һәм сатып алынган элиталы орлыклар өчен субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана.

6. Сатып алынган элиталы орлыклар чыгымнарының бер олешен каплауга субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын китерү шартнамәләрен;

в) түләүче банк таныклаган түләү йөкләмәсен;

г) товар-транспорт накладноен;

д) туры килү сертификатын;

е) карантин сертификаты һәм фитосанитар контроль актын (орлыкларны Татарстан Республикасыннан читтән керткәндә);

ё) бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык раслаган форма

буенча төзелгән исәп-хисап белешмәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләрен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр таныклый.

7. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп, бирелергә тиешле субсидияләр турында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырылган исәп-хисап белешмәләрен таныклый һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру;

бюджет йөкләмәләренең калган лимиты булмау.

8. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора.

9. Министрлык Министрлык белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

10. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылса, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан тапшырыла торган һәм авыл

хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

15. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны (1 гектарга кимендә 800 агач), җиләк һәм җимеш куаклары питомниклары утырту һәм аларны товар буларак яраклы уңыш бирә торган яшькә җиткәнче карау белән шогыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен, интенсив типтагы бакчаларны утырту һәм карау чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, күпьеллык җиләк һәм җимеш куакларының үсентеләре).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрне сайлап алу критерийлары:

күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләре утыртылган җир кишәрлекләренең милектә яки арендалау шартларында булуы;

бакча утырту проекты булу;

күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләрен утыртуны елына кимендә 1 гектар мәйданда башкару;

агымдагы финанс елы башында кимендә 1 гектар күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләре булу.

3. Субсидияләр бетерелү стадиясендәге яки үз-үзен тәэмин итә алмаган (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелми.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү максатлары:

күпьеллык җимеш һәм җиләк куакларының үсентеләре мәйданнарын арттыру;

җиләк-җимеш культуралары продукциясен җитештерүне арттыру.

5. Күпьеллык җимеш һәм җиләк үсентеләрен утыртуга һәм карап үстерүгә субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана..

6. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

бакча утырту проектын;

күпьеллык җимеш һәм җиләк куаклары үсентеләрен утырту һәм карап үстерү эшләрен башкаруга подряд шартнамәсен (подрядчы оешманы җәлеп иткән очракта);

күпьеллык җимеш һәм җиләк куаклары үсентеләрен утырту һәм карап үстерү эшләрен башкару актын;

күпьеллык җимеш һәм җиләк куаклары үсентеләрен утырту һәм карап үстерү буенча башкарылган эшләр хакы турында Россия Дәүләт статистика комитетының 1999 елның 11 ноябрендәге 100 номерлы карары белән расланган КС-3 формасы буенча белешмәне;

бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык раслаган форма буенча төзелгән исәп-хисап белешмәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләрен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр таныклый.

7. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш коненнән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп, бирелергә тиешле субсидияләр турында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырылган исәп-хисап белешмәләрен таныклый һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидияләр бирүдән баш тарту очен нигезләр:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру;

бюджет йөкләмәләренең калган лимиты булмау.

8. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора.

9. Министрлык Министрлык белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

10. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә

торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылса, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дереслеге очен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

15. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
4 нче кушымта

# 2015 елда файдаланылмый торган иске бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультиваңияләү чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) файдаланылмый торган иске бакчаларны топләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультивацияләү чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

төпләнергә һәм тамырлардан арындырылырга тиешле файдаланылмый торган иске бакчалар утыртылган җир кишәрлекләренең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр милкендә яки арендалау шартларында булуы;

күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә яңа бакча утырту проекты булу.

3. Субсидияләр бетерелү стадиясендәге яки үз-үзен тәэмин итә алмаган (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелми.

4. Субсидияләр бирү максатлары бакчаларны яңартудан, аларның мәйданнарын саклап калудан һәм арттырудан, җиләк-җимеш культураларының уңышын һәм аларны җитештерүне арттырудан гыйбарәт.

5. Утырту елыннан алып исәпләгәндә 30 елдан арткан бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультиваңияләү өчен субсидияләр ставкалары Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланa.

6. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) тамырлардан арындырылган мәйданнарда яңа бакча утырту проектын;

в) подряд шартнамәсен (плдрядчы оешма җәлеп ителгән очракта);

г) иске бакчаларның яше һәм мәйданы турында мәгълүматны үз эченә алган хуҗалыкларның еллык хисапларын;

д) бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультивацияләү эшләре башкарылу турында актны;

е) бакчаларны төпләү һәм тамырлардан арындырылган мәйданнарны рекультивацияләүнең буенча башкарылган эшләр һәм чыгымнар хакы турында Россия Дәүләт статистика комитетының 1999 елның 11 ноябрендәге 100 номерлы карары белән расланган КС-3 формасы буенча белешмәне;

ж) бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмәсен.

Тапшырылган документларның күчермәләрен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр таныклый.

7. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган конне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый (документларны карау срогы гаризаны теркәгән коннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел);

в) күрсәтелгән документларга нигезләнеп, бирелергә тиешле субсидияләр турында авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырылган исәп-хисап белешмәләрен таныклый һәм Министрлыкка тапшыра.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру;

бюджет йокләмәләренең калган лимиты булмау.

8. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора.

9. Министрлык Министрлык белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

10. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылса, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

15. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
5 нче кушымта

2015 елда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) сөт чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) (алга таба – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр) сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) югары сортлы һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенә, һәм (яки) кәҗә сөтенә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - сөт, субсидияләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерие Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарә) мөрәҗәгать итү аеның 1 числосына сыер һәм (яки) кәҗә башлары булган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сөт сатуны һәм (яки) үзендә эшкәртүне гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

3. Субсидияләр бетерелү стадиясендәге яки үз-үзен тәэмин итә алмаган (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелми.

4. Субсидияләр бирү максаты авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең үзләре тарафыннан сөт җитештерүгә ярдәм итүдән гыйбарәт.

5. Субсидиянең күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә,

$$W_i = W_{Hi} + W,$$

монда:

$W_{Hi}$ – югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелә торган субсидия күләме;

W – кәҗә сөтенә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелә торган субсидия күләме;

6. Югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелә торган субсидия күләме ($W_{Hi}$) агымдагы финанс елында түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{Hi} = S_H \times V_{Hi},$$

монда:

$S_H$ - сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенең 1 литрына (килограммына) ставка, ул хисап чорында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөте күләмнәреннән чыгып Министрлык тарафыннан раслана;

$V_{Hi}$- авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән югары һәм (яки) беренче сортлы сыер сөтенең күләме.

7. Кәҗә сөтенә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелә торган субсидия күләме (W) агымдагы финанс елында түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = S \times V,$$

монда:

S - сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән кәҗә сөтенең 1 литрына (килограммына) ставка, ул хисап чорында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән кәҗә сөте күләмнәреннән чыгып Министрлык тарафыннан раслана;

V- авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан сатылган һәм (яки) үзенә эшкәртү өчен җибәрелгән кәҗә сөтенең күләме.

8. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Идарәләргә түбәндәге документларны тапшыралар:

а) түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча сыер сөтенең һәм (яки) кәҗә сөтенең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан сатылуы һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелүе фактын раслый торган документлар реестрын.

Үзендә сөт эшкәртү мөмкинлекләре булган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр хуҗалык эчендә йөри торган накладнойларның (сөт ташу өчен) таныкланган күчермәләрен, үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән товар сөтнең планлаштырылган үзкыйммәте күрсәтелгән бухгалтерия белешмәсен һәм сөт продукциясенә куллану өчен яраклылык сертификатын тапшыралар;

в) 2015 елның 1 гыйнварына сыер һәм (яки) кәҗә башлары турында рәсми статистик хисаплар нигезләнеп төзелгән мәгълүматны;

г) субсидияләр бирү турында мөрәҗәгать иткән айның 1 нче числосына сыер һәм (яки) кәҗә башлары турында рәсми статистик хисаплар нигезләнеп төзелгән мәгълүматны;

д) бухгалтерлык хисапларына нигезләнеп, Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан узган елда сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән терлекчелек продукциясенең сыйфаты турындагы белешмәләрне;

е) әлеге пунктның “б” пунктчасында күрсәтелгән документларга нигезләнеп, сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) сыер сөтенә һәм кәҗә сөтенә чыгымнарның бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмәләрен;

ж) сөт җитештерү һәм сату турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча белешмәләрне.

9. Идарә:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел;

в) әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларга нигезләнеп, Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча түбәндәгеләрне төзи һәм Министрлыкка тапшыра:

Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча физик авырлыгындагы сыер сөтен һәм (яки) кәҗә сотен сатуның һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрүнең Министрлык тарафыннан расланган форма буенча җыелма реестрларын;

Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен җибәрелгән 1 литр (килограмм) сыер сөтенә һәм кәҗә сөтенә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджеттан субсидияләр бирү өчен Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмәләрен;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүче тарафыннан 2015 елда сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү очен җибәрелгән терлекчелек продукциясенең сыйфаты турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча белешмәләрне;

сөт җитештерү һәм сату турында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча белешмәләрне.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру;

бюджет йөкләмәләренең калган лимиты булмау.

10. Министрлыкның зык-төлек базарын үстерү бүлеге, Идарәләрнең җыелма реестрларына нигезләнеп, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча ай саен Татарстан Республикасы буенча җыелма реестр төзи һәм аны хисап аеннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенә тапшыра.

11. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган Идарәләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка тапшырылган бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәләре субсидияләр күчерү өчен нигез булып тора.

12. Министрлык Министрлык белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

13. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылса, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

16. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

17. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

18. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
6 нчы кушымта

2015 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип, ярдәмче шәхси хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр).

2. Субсидияләр алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрен сайлап алу критерийлары:

дәүләт нәсел регистрында теркәлгән, нәселле терлекчелек оешмаларыныкы булган авыл хуҗалыгы терлекләренең нәселле көтүләре булу;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдә авыл хуҗалыгы терлеге булу.

3. Субсидияләр бетерелү стадиясендәге яки үз-үзен тәэмин итә алмаган (банкрот) дип танылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бирелми.

4. Субсидияләр бирү максаты нәселле терлекнең баш санын арттырудан, артым алудан һәм авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыруны арттырудан гыйбарәт.

5. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә, шул исәптән ит нәселле мөгезле эре терлеккә ярдәм итүгә субсидияләр (алга таба – нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә субсидияләр) түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

а) нәселле терлекчелеккә ярдәм итү, шул исәптән:

ит нәселле мөгезле эре терлегеннән тыш, авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башларын асрау;

16 айдан зуррак, нәсел калдыра алу сыйфатына тикшерелгән яки бу сыйфатны тикшерү процессында булган сөт нәселле орлык үгезләрен (алга таба – сөт нәселле орлык үгезләре) асрау;

сөт бирүне һәм хайванны чыгарган ил тарафыннан бирелгән геннар буенча бәяләмә нәтиҗәләре буенча технологик сыйфатларны яхшырта торган сөт нәселле орлык үгезләрен сатып алу, шул исәптән импорттан;

сөт мөгезле эре терлегенең нәселле бозауларын сатып алу;

сөт нәселле орлык үгезләренең орлыкларын сатып алу;

сөт нәселле мөгезле эре терлеге эмбрионнарын сатып алу, шул исәптән импорттан;

б) ит нәселле мөгезле эре терлегенә ярдәм итү, шул исәптән:

ит нәселле мөгезле эре терлегенең ана башларын асрау;

16 айдан зуррак, нәсел калдыра алу сыйфатына тикшерелгән яки бу сыйфатны тикшерү процессында булган ит нәселле орлык үгезләрен (алга таба –

ит нәселле орлык үгезләре) асрау;

ит бирүне һәм хайванны чыгарган ил тарафыннан бирелгән геннар буенча бәяләмә нәтиҗәләре буенча технологик сыйфатларны яхшырта торган ит нәселле орлык үгезләрен сатып алу, шул исәптән импорттан;

ит мөгезле эре терлегенең нәселле бозауларын сатып алу;

ит нәселле орлык үгезләренең орлыкларын сатып алу.

6. Нәселле терлекчелеккә ярдәмгә акчалар Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан расланган ставкалар буенча Россия Федерациясе субъекты өчен каралган акчалар кысаларында түбәндәге максатларга биреләләр:

а) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары тәкъдиме буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә - шартлы рәвештә 1 баш ставкасы буенча (сөт һәм ит өчен терлек үрчетүдә - хисап финанс елында тере бозау китергән 1 башка исәпләгәндә) авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башын асрауга. Авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башын шартлы рәвештә алынган баш исәбенә күчерү коэффициенты Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә;

б) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары тәкъдиме буенча Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыру оешмаларына – 1 баш ставкасыннан чыгып нәсел үгезләрен асрауга;

в) авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыра торган оешмаларга – дәүләт ннәсел регистрында теркәлгән нәселле көтүләрдән нәсел үгезләрен сатып алуга, шул исәптән 1 кг тере масса ставкасыннан импорттан;

г) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә - дәүләт ннәсел регистрында теркәлгән нәселле көтүләрдән ит нәселле мөгезле эре яшь терлеген сатып алуга, шул исәптән 1 кг тере масса ставкасыннан импорттан;

д) авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыра торган оешмаларга – нәселлек сыйфаты тикшерелгән нәсел үгезләренең орлыкларын 1 доза ставкасы буенча сатып алуга, шул исәптән импорт буенча;

е) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы терлеген ясалма орлыкландыру оешмаларына – сөт мөгезле эре терлеге эмбрионнарын 1 данәгә исәпләнгән ставка буенча сатып алуга.

7. Нәселле терлекчелеккә ярдәмгә субсидияләр алу өчен, шул исәптән:

7.1. Авыл хуҗалыгы терлегенең нәселле ана башларын асрауга, сөт нәселле орлык үгезләрен асрауга, ит мөгезле эре терлегенең нәселле ана башларын асрауга, ит нәселле орлык үгезләрен асрауга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыралар:

а) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмәсен;

б) фермада терлекнең һәм кош-кортның әйләнеше турында хуҗалык эчендә йөри торган хисапның күчермәсен;

в) 2014 елга рәсми статистика хисабы нигезләнеп эшләнә торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

7.2. Сөт нәселле орлык үгезләрен, шул исәптән импорттан сатып алуга, сөт мөгезле эре терлегенең нәселле бозауларын, шул исәптән импорттан сатып алуга, сөт нәселле орлык үгезләренең орлыкларын, шул исәптән импорттан сатып алуга, сөт нәселле мөгезле эре терлеге эмбрионнарын, шул исәптән импорттан сатып алуга, ит нәселле орлык үгезләрен, шул исәптән импорттан сатып алуга, итт мөгезле эре терлегенең нәселле бозауларын, шул исәптән импорттан сатып алуга, сөт нәселле орлык үгезләренең орлыкларын, шул исәптән импорттан сатып алуга авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыралар:

а) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмәсен;

б) аванс түләүләрен дә кертеп, товарлар өчен түләү буенча банк өземтәләренең һәм түләү йөкләмәләренең түләүче банк тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

в) шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомостенең, нәсел эшләре белән шөгыльләнә торган оешма биргән нәсел таныклыкларының яки паспортларының (10 баштан артык сатып алынса, нәсел таныклыкларының яки паспортларының реестры тапшырыла) күчермәсен;

г) фермада терлекнең һәм кош-кортның әйләнеше турында хуҗалык эчендә йөри торган хисапның күчермәсен;

ж) 2014 елга рәсми статистика хисабы нигезләнеп эшләнә торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан таныклана.

7.3. Министрлык:

а) субсидияләр бирү соралган гаризаларны алар алынган көнне журналга терки, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер сугылган булырга тиеш;

б) әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документларны карау срогы гаризаны теркәгән көннән алып 15 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел.

Субсидияләр бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру;

бюджет йөкләмәләренең калган лимиты булмау.

8. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына күчерә.

Әлеге тәртипнең 7 пунктына ярашлы рөвештә тапшырылган документлар субсидияләр күчерү очен нигез була.

9. Министрлык Министрлык белән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр арасында Министрлык раслаган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзи.

10. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

11. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

12. Әлеге Тәртипнең 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылса, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

13. Министрлык авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

14. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан тапшырыла торган һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

15. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.